СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» сентябрь 2024ел № 116

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының " 29.06.2022 елның № 51 нче “Мөлкәткә салым турында” гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү, Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм тәртибен, датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Яңгул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының «Мөлкәткә салым турында» 29.06.2022 елның, № 51 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 нче пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләрдән һәм сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш) 2%, әлеге кодексның 378.2 се, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

1.2. 2.6 пунктчасы өстәргә.

Эчтәлеге түбәндәгечә: «Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 2025-2027 еллар чорына 1,2%»;

1.3. 2.6 пунктчаны 3 пункт дип санарга, 3 пунктны 4 пункт дип санарга, 4 пунктны 5 пункт дип санарга, 5 пунктны 6 пункт дип санарга, 6 пунктны 7 пункт дип санарга.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru)

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гыйльфанов